ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.06.2019 Казан ш. № 70-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 07 декабрендәге 517-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы карамагындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 2015 елның 07 декабрендәге 517-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең 2017 елның 14 ноябрендәге 481-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе каршында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупциячел торышка сабырсызлык формалаштыру»;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары нигезендә, Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый советта каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциясез оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.»

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасының
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г.Хисаметдинов